# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Чупай торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

20 ноябрь 2025 № 6

20.03.2025 № 33-ФЗ «Бердәм җәмгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең Федераль законының 45 нче, 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Әтрәкле авыл җирлеге" Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге Чупай торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге Чупай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, МХОда катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, МХОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Чупай торак пунктында җир асты сулары чыганакларын (чишмәләр) төзекләндерү (чишмәне ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу);
2) Чупай торак пунктының башка территорияләрен төзекләндерү (милли бәйрәм үткәрү урынында утыргычлар урнаштыру өчен төзелеш материаллары сатып алу).

3. Әлеге карарны Әтрәкле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы

А.М. Гыйльмуллин

Совет АТРЯКЛИНСКОГО сельского поселения
ОГРН 1021605552836
ИНН 1628002869